| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

г. Буинск

2020 елның 30 октябре 91-п номерлы

Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка
ярдәм күрсәтү һәм үстерү мәсьәләләре буенча
Координация советы турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2017 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү эшен оештыру максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Буа муниципаль районы башлыгының 2019 елның 11 июнендәге 57-п номерлы «Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча Координация советы төзү турында» карары белән расланган Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү һәм үстерү мәсьәләләре буенча Координация советы турындагы нигезләмәгә ( алга таба- Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«4.4. Совет рәисе булмаган чорга, Совет рәисе урынбасары:

- рәсми рәвештә Советны Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында, муниципаль районның җирле үзидарә органнарында, иҗтимагый һәм башка оешмаларда, шулай ук чит дәүләтләр органнарында һәм оешмаларында һәм халыкара оешмаларда тәкъдим итә;
- Совет эше белән җитәкчелек итә;
- Совет утырышын алып бара;
- Совет карарларын үтәүне оештыра.»;

1.2. Нигезләмәнең 5.4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Совет карарлары Совет утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыштан соң 5 көн эчендә рәсмиләштерелә һәм Совет рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Совет әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш.

Совет карарлары тәкъдим характерында.

Совет әгъзалары утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Камартдинов